| **УКАЗ**<br>РАИСА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>РӘИСЕ<br>**УКАЗЫ** |
|---|---|---|

**Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 19 октябрендәге 757 номерлы Указын Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыру максатларында кайбер мәгълүматны бастырып чыгаруны, таратуны тыю турында**

Татарстан Республикасы территориясендә җәмәгать тәртибен саклауны көчәйтү һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 19 октябрендәге 756 номерлы Указы белән бәйле рәвештә Россия Федерациясе субъектларында гамәлгә ашырыла торган чаралар турында» 2022 елның 19 октябрендәге 757 номерлы Указы нигезендә **карар бирәм**:

1. Массакүләм мәгълүмат чараларында, мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, шул исәптән «Интернет» челтәрендә, социаль челтәрләрдә, тиз хәбәр алмашу сервисларында түбәндәге мәгълүматны, фото- һәм видеоматериалларны да кертеп, бастырып чыгаруны, таратуны тыярга:

а) Татарстан Республикасы территориясендә пилотсыз һава суднолары (пилотсыз (һава) очкыч аппаратлар) кулланылуы һәм аларны куллануның нәтиҗәләре турында, аларның төрен, җибәрелгән, табылган, төшкән урынын, очыш траекториясен тәңгәлләштерергә, алар һөҗүм иткән урыннарны (объектларны), аларның объектларны җимерү фактын һәм алар тарафыннан салынган зыян характерын билгеләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүматны да кертеп;

б) Татарстан Республикасы территориясендәге пилотсыз һава судноларына (пилотсыз (һава) очкыч аппаратларына) каршы гамәл кылу чаралары (системалары), шул исәптән һавадан янаган куркынычтан саклану һәм радиоэлектрон көрәш чаралары (системалары) кулланылу һәм аларны куллануның нәтиҗәләре турында;

в) Татарстан Республикасы территориясендәге пилотсыз һава судноларына (пилотсыз (һава) очкыч аппаратларына) каршы гамәл кылу корылмалары, чаралары (системалары), шул исәптән һавадан янаган куркынычтан саклану һәм радиоэлектрон көрәш чаралары (системалары) урнашкан урыннар турында;

г) әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән урыннарны ачыкларга ярдәм итә торган.

2. Әлеге Указның 1 пункты нигезендә кертелгән тыю әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән мәгълүматны федераль башкарма хакимият органнары, аларның Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бара торган территориаль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары тарафыннан массакүләм мәгълүмат чараларында, мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, шул исәптән «Интернет» челтәрендә, социаль челтәрләрдә, тиз хәбәр алмашу сервисларында (алга таба – рәсми чыганаклар) бастырып чыгару, тарату, шулай ук аны рәсми чыганакларга сылтама белән тарату очракларына кагылмый.

3. Әлеге Указ нигезендә кертелгән тыю Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 19 октябрендәге 756 номерлы Указы белән бәйле рәвештә Россия Федерациясе субъектларында гамәлгә ашырыла торган чаралар турында» 2022 елның 19 октябрендәге 757 номерлы Указының 5 пункты нигезендә кертелгән режим (төп әзерлек дәрәҗәсе) туктатылганга кадәр гамәлдә була.

4. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2025 ел, 29 август
№ 695